РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17» апрель 2020 ел Олы Кайбыч авылы № 232

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итү өлкәсендә коммуналь инфраструктура системаларына карата концессион килешүләр төзү һәм әлеге объектларны концессиягә тапшыру буенча чаралар планын ("ЮЛ КАРТАСЫ" ) раслау турында

Россия Федерациясе Граждан кодексына, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, су белән тәэмин итү системалары объектлары буенча концессион килешүләр төзү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Ф.Ш. Әхмәтовның докладын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләрендә су белән тәэмин итү өлкәсендә коммуналь инфраструктура системаларына карата концессион килешүләр төзү һәм әлеге объектларны концессиягә тапшыру буенча чаралар планын (»ЮЛ КАРТАСЫ") расларга

2.Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына:

Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Кайбыч муниципаль районының интернет-телекоммуникация челтәрендәге түбәндәге веб-адрес буенча http://kaybici.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Ф.Ш. Әхмәтовка йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин